КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 август

г.Казань

№ 597

2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 14 август, 597 нче
карары белән расланды

2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең
чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә
финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына
башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү (алга таба шул ук эзлеклелектә – муниципаль берәмлек, башка бюджетара трансфертлар) механизмын, максатын һәм шартларын билгели.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюдже йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бүлеп бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

локаль чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләре билгеләнә торган муниципаль хокукый акт булу;

әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә Министрлык белән муниципаль берәмлек арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлек Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка (алга таба – заявка);

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль хокукый акт күчермәсе.

7. Министрлык:

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны кергән көнендә терки;

заявка теркәлгән көннән алып җиде эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә башка бюджетара трансфертлар бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

башка бюджетара трансфертлар бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне эчендә башка бюджетара трансфертлар бирү яисә бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында муниципаль берәмлеккә язма рәвештә хәбәр итә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

Муниципаль берәмлек, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алган көннән алып 10 эш көне эчендә документларны кабат бирергә хокуклы.

9. Башка бюджетара трансфертлар аларны бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап бирү сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану шартлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

Килешү буенча йөкләмәләр үтәлмәгән яки тиешенчә үтәлмәгән өчен якларның җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансфертлар бирүнең нәтиҗәсе – Килешү төзелгән көннән башлап 12 ай дәвамында яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тоту.

12. Башка бюджетара трансфертларны файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан Килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткечләрен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырырла.

13. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан Килешү төзелгән көннән алып 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

14. Муниципаль берәмлек Килешүдә билгеләнгән срок эчендә Министрлыкка килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында, башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыра.

15. Муниципаль берәмлек тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының үтәлеше өчен законнар нигезендә җавап бирә.

16. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2026 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Әгәр башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән булса, әлеге акча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

17. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып 30 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена түбәндәге очракларда тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш:

муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылганда, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланганда;

муниципаль берәмлек тарафыннан финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап Килешүдә билгеләнгән срокта тапшырылмаганда;

муниципаль берәмлек тарафыннан Килешүдә билгеләнгән срокларда башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгәндә.

18. Башка бюджетара трансфертлар һәм (яисә) муниципаль берәмлек тарафыннан аларны бирү шартлары максатчан файдаланылмаган очракта, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 16, 17 пунктлары нигезендә Татарстан

Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

19. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртип һәм Килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

20. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылуын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

______________________________________

______________________________________

(муниципаль берәмлек җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (тулысынча)

______________________________________

____________________________ тан (дан)

2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 14 август, 597 нче карары белән расланган 2025 елда Казан шәһәрендәге яңгыр канализациясенең чистарту корылмаларын карап тотуга бәйле чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслау өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ________ ел, ________________, _______ нчы боерыгы нигезендә ______________________________________________________________

(муниципаль берәмлек исеме)

_____________________________________________________________________________________

(чараның исеме, башка бюджетара трансферт бирү максатлары)

_____________________________________________________________________________________

_____________________(____________________________________) сум ___ тиен күләмендә

(сумма цифрлар белән) (сумманы тутырып язу)

бирүгегезне сорыйм.

Бу заявкада бирелгән белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дөрес булмаган белешмә һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләр буенча башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылган очракта, бирелгән бүтән бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарырга тиеш булуым турында хәбәрдармын.

_______________________________________________________________ га карата

(муниципаль берәмлек исеме)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризамын.

Җитәкче
(аның вазыйфаларын башкаручы зат) ________/_______________________/
(имза) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.

Дата: 20__ ел, «__» __________

_________________________________